**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2016 ел, 27 июль | № 518

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү буенча иҗтимагый оешмалар башлангычларына булышлык күрсәтүгә грантлар бирү турында нигезләмәне раслау хакында» 2015 ел, 7 август, 573 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү буенча иҗтимагый оешмалар башлангычларына булышлык күрсәтүгә грантлар бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү буенча иҗтимагый оешмалар башлангычларына булышлык күрсәтүгә грантлар бирү турында нигезләмәне раслау хакында» 2015 ел, 7 август, 573 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның телләрен саклау һәм үстерү буенча иҗтимагый оешмалар башлангычларына булышлык күрсәтүгә грантлар бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Дәүләт программасы нигезендә, бу максатларга бүленә торган акча чикләрендә 2016 елда биш грантның һәрберсенең күләме 200 000 (ике йөз мең) сум тәшкил итә.»;

13 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Заявка һәм аңарга теркәлә торган документлар тегелгән, аларга сан куелган һәм мөһер вә иҗтимагый оешманың вәкаләтле заты имзасы белән таныкланган булырга тиеш.»;

25 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Комиссия карарлары утырышта катнашкан Комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.»;

27 пунктка «утырышта рәислек иткән» сүзләреннән соң «һәм рәис булмаганда аның вазыйфаларын башкарган,» сүзләрен өстәргә;

33 пунктта «кире кайтару тәртибе» сүзләре «кире кайтару очраклары» сүзләренә алмаштырырга;

36 һәм 40 пунктларда «гамәлдәге» сүзен төшереп калдырырга;

41 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«41. Грантның хисап финанс елында файдаланылмаган өлеше Килешүдә каралган очракларда хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты керемәнә кире кайтарылырга тиеш. Грант алучы грантның хисап финанс елында файдаланылмаган өлешен кире кайтару вакытларын бозганда Вәкаләтле орган 15 көн эчендә әлеге акчаны законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кайтарту чараларын күрә.»;

42 пунктта «белән билгеләнгән тәртиптә» сүзләрен «нигезендә» сүзенә алмаштырырга;

43 пунктта «һәм нәтиҗәле» һәм«гамәлдәге» сүзләрен төшереп калдырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков